**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 апрель № 233

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2015 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен;

2015 елда икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәк җитештерүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елга агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган финанслау күләмнәрен бүлүдә:

4 нче юлдагы «10 000,0» саннарын «5 200,0» саннарына алыштырырга;

9 нчы юлдагы «350 000,0» саннарын «300 000,0» саннарына алыштырырга;

12 нче юлдагы «373 555,6» саннарын «463 555,6» саннарына алыштырырга;

13 нче юлдагы «135 000,0» саннарын - «64 800,0» саннарына, «120 000,0» саннарын «49 800,0» саннарына алыштырырга;

16 нчы юлдагы «150 000,0» саннарын - «155 000,0» саннарына, «100 000,0» саннарын «105 000,0» саннарына алыштырырга;

17 нче юлдагы «1 940 000,0» саннарын «1 872 500,0» саннарына

алыштырырга;

27 нче юлдагы «100 000,0» саннарын «70 000,0» саннарына алыштырырга;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 30 – 31 нче юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «30. | Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 11 900,0 |
| 31. | Икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәк җитештерүгә бәйле булган чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 67 500,0»; |

«Барлыгы» юлындагы «6 095 755,6» саннарын «6 047 655,6» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә чиста канлы менге токымнардан булган нәсел атлары үрчетүгә бәйле булган чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенең 5 нче пунктындагы «40,7» саннарын «41,585» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сөтле токымлы нәселле мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү.»;

түбәндәге эчтәлекле 24.1 нче пункт өстәргә:

«24.1. 2015 елда сөтле токымлы нәселле мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр нәсел репродукторларына бер килограмм тере авырлык өчен 144,0 сум исәбеннән чыгып бирелә.

Нәсел репродукторларына сөтле токымлы нәселле мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

нәсел репродукторларының дәүләт нәсел регистрында теркәлү турындагы таныклыгы булу;

күп ана баш мөгезле эре терлек булу.

Субсидия алу өчен нәсел репродукторлары Идарәгә түбәндәге документларны кертә:

Россия Федерациясенең Статистика буенча дәүләт комитеты раслаган форма буенча фермада терлек һәм кош-корт хәрәкәте турында хуҗалык эчендәге хисап күчермәсен;

банк – алучы таныклаган түләү йөкләмәсен, шартнамә, исәп-фактура, 2015 елда сөтле токымлы мөгезле эре терлек кайтартуга йөкнамә күчермәләрен;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык расланган форма буенча

белешмә-исәп-хисап.»;

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада:

түбәндәге эчтәлекле 20 нче юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «20. | Сөтле токымлы нәселле мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 90 000,0»; |

«Барлыгы» юлындагы «373 555,6» саннарын «463 555,6» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә теркәлгән кушымтада:

«Өстәмә лимит (Төбәк азык-төлек фондын формалаштыру максатларында тапшырылган ашлык өчен)» юлындагы «140 000» саннарын «72 500» саннарына алыштырырга;

«Барлыгы» юлындагы «1 940 000» саннарын «1 872 500» саннарына алыштырырга;

әлеге карарга 2015 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен һәм 2015 елда икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәк җитештерүгә бәйле булган чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\233.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 26 февраль, 120 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 10 апрель, 233 нче
карары редакциясендә)

## 2015 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2015 елда Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр (алга таба – катнашучылар, субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр алуда катнашучыларны сайлап алу критерие булып авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм реализацияләү тора.

4. Субсидияләр бирү максаты – 2015 елда Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә үткәрелә торган ярминкәләргә авыл хуҗалыгы товарлары китерүне стимуллаштыру.

5. Субсидияләр бирү шарты булып 2015 елның 17 гыйнварыннан 28 мартына кадәрге чорда Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә авыл хуҗалыгы продукциясе реализацияләү ярминкәләрендә катнашу тора.

6. Субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = (Р * (Н + Н*(К1 + К2) * Ц)/100,$$

монда:

С – субсидияләр күләме, сум;

Р – юл йөрү кәгазьләре мәгълүматлары буенча транспорт чарасының юл йөрү күрсәткече, километр;

Н – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары сарыф итү нормалары»

методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 ел, 14 март, АМ-23-р боерыгы нигезендә ягулык сарыф итү база нормасы, 100 километрга литр;

К1 - Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары сарыф итү нормалары» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 ел, 14 март, АМ-23-р боерыгы нигезендә автотранспортның елның кышкы чорында эшләгәндә ягулык сарыф итү база нормасын арттыру коэффициенты;

К2 - Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары сарыф итү нормалары» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 ел, 14 март, АМ-23-р боерыгы нигезендә автомобиль мәҗбүри туктап торганда ягулык сарыф итү база нормасын арттыру коэффициенты;

Ц – ярминкәләр үткәрелгән көнгә ярминкәдә катнашучы килгән урын буенча Татарстан Республикасы районнарында һәм шәһәрләрендә ягулык-майлау материаллары бәясе, 1 литр өчен сум.

7. Субсидияләр алу өчен катнашучылар Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының үзләре урнашкан урын буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр), ә «Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциягә карамаган оешмасы (алга таба – Татарстан кулланучылар берлеге) әгъзалары булып торучы кулланучылар җәмгыятьләре Татарстан кулланучылар берлегенә түбәндәге документларны кертә:

катнашучының түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

2015 елда Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә халыкка реализацияләү өчен авыл хуҗалыгы продукциясе кайтарту фактын раслый торган юл йөрү кәгазьләрен, транспорт чаралары реестрын;

субсидияләр бирү өчен Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисаплар.

8. Идарәләр һәм Татарстан кулланучылар берлеге:

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны бит саннары куелырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиешле журналда алар кергән көндә терки;

тапшырылган документларны бу Тәртипнең 7 нче пунктына туры килү-килмәү буенча гариза теркәлгән көннән 20 көн эчендә карый һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карарлар кабул итә;

Кертелгән документлар нигезендә:

Идарәләр Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча катнашучыларга бирелергә тиешле (кулланучылар җәмгыятьләреннән тыш) субсидияләр турында Министрлык раслаган форма буенча җыелма белешмә-исәп-хисаплар төзи һәм Министрлыкка кертә;

Татарстан кулланучылар берлеге Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча кулланучылар җәмгыятьләренә бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык раслаган форма буенча җыелма белешмә-исәп-хисаплар төзи һәм Министрлыкка кертә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы булмаган комплектын кертү;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан акча калмау.

9. Министрлык катнашучылар белән субсидия бирү турында Министрлык раслаган форма буенча килешүләр төзи.

10. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм акчаны бу Тәртипнең 8 нче пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси исәпләренә һәм Татарстан кулланучылар берлеге хисап исәбенә акча күчерүне гамәлгә ашыра.

Идарәләр һәм Татарстан кулланучылар берлеге Министрлыкка кертkән җыелма белешмә-исәп-хисаплар субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора. Идарәләр һәм Татарстан кулланучылар берлеге бюджет акчасын алган көннән биш көн эчендә субсидияләрне катнашучыларның хисап исәпләренә күчерә.

11. Бирелгән субсидияләр субсидияләрдән максатчан файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактлары ачыкланганнан соң Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш.

12. Субсидияләр бирү турындагы килешүләрдә күздә тотылган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр субсидия алучылар тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш.

13. Бу Тәртипнең 11 нче һәм 12 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

14. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартын, максатын һәм тәртибен үтәүләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

15. Идарәләр һәм Татарстан кулланучылар берлеге – Министрлыкка, шулай ук катнашучылар кертә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә тиешенчә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

16. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 26 февраль, 120 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 10 апрель, 233 нче
карары редакциясендә)

2015 елда икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәк җитештерүгә бәйле булган чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2015 елда Татарстан Республикасы территориясендә социаль икмәк җитештерү белән шөгыльләнүче икмәк пешерү предприятиеләренә он сатып алуга бәйле булган чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр (алга таба – субсидияләр, предприятиеләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр алу өчен предприятиеләрне сайлап алу критерие булып түбәндәгеләр тора:

социаль икмәк пешереп чыгару өчен кимендә 100 кв.метр күләмендә җитештерү мәйданнары булу;

җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру.

4. Предприятиеләргә субсидияләр бирүнең максаты – социаль әһәмияткә ия булган икмәккә тотрыклы бәяләрне саклау.

5. Предприятиеләргә субсидияләр бирү шарты булып айга кимендә 1 тонна социаль икмәк җитештерү тора.

6. Субсидияләр предприятиеләргә 1 сортлы бер килограмм бодай онының базар кыйммәте белән фондның 1 сортлы бодай онының билгеләнгән бәясе арасындагы аерма буларак, ләкин бер килограмм бәясен 4 сумнан да артырмыйча бирелә.

7. Субсидияләр алу өчен предприятиеләр Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресларын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

1 сортлы бодай оны кайтарту турында шартнамә;

он сатып алуга товар-транспорт йөкнамәсен;

он өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәсен;

бер айга социаль икмәк (1 сортлы «Сельский», «Дарницкий», «Белый» икмәге) җитештерү күләме турында мәгълүмат;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисаплар.

8. Министрлык:

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны бит саннары куелырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиешле журналда алар кергән көндә терки;

тапшырылган документларны гариза теркәлгән көннән 20 көн эчендә бу Тәртипнең 7 нче пунктына туры килү-килмәү буенча карый һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы булмаган комплектын кертү;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан калган акча булмау.

9. Министрлык предприятиеләр белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

10. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм акчаны бу Тәртпнең 8 нче пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән предприятиеләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментында ачылган шәхси исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

11. Бирелгән субсидияләр бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын, субсидияләрдән максатчан файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактлары ачыклану буенча, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

12. Субсидияләр бирү турындагы килешүләрдә күздә тотылган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрне субсидияләр алучылар хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарып бирергә тиеш.

13. Бу Тәртипнең 11 нче һәм 12 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

14. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатын һәм тәртибен үтәвенә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

15. Предприятиеләр Министрлыкка кертә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

16. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---